ГЛАВА БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Байряки-Тамак, ул.Новая, д.37, ,
423964

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘ-ТАМАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Бәйрәкә-Тамак авылы, Яңа урамы,
37 йорт, 423964

Тел.:(85593) 5-13-25, факс:5-13-24, e-mail: Btam.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

N 3 14 .11.2022 ел

Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Подгорный бистәсендә 2023 елда үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 6 октябрендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең 2019 елның 17 июлендәге 8 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниөипаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Уставының 14, 81 маддәләре, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 10 сентябрендәге 11 санлы карары белән расланган Нигезләмә нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Подгорный поселогында Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Подгорный бистәсе, Үзәк урамы, 22А йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасы янында 2022 елның 26 ноябренә 11.00 сәгатьтә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Подгорный бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2023 елда үзара салым кертүгә 500 (биш йөз) сум күләмендә ризалыгыгыз бармы, моңа көндезге формада белем алучы студентлар, I төркем инвалидлар; БВ сугышында катнашучылары, Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр керми һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән сез ризамы:

- Подгорный бистәсе, Нагорная урамында су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләү (материаллар, җиһазлар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Подгорный торак пунктында коры агачларны кисү, территориясен чистарту. (килешү буенча эш өчен түләү);
- Подгорный торак пунктында «Юбилейный» паркы территориясен төзекләндерү (тренажерлар сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);
- җирлек юлларын карап тоту (юлларны кардан чистарту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка чыгарырга, веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» на урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru; www.yutaza.tatar.ru веб-адрес буенча Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында куярга.http://www.yutaza.tatar.ru

4. Әлеге карар басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

"Бәйрәкәтамак авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы Ф.В.Әхмәтов